КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 май г.Казань № 465

2022 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау үзенчәлекләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2022 ел, 28 февраль, 175 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларынраслый торган норматив хокукый актларны (алга таба – административ регламентлар) әзерләгәндә һәм раслаганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2022 ел, 28 февраль, 175 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында вәкаләтле оешма тарафыннан эшләү, килештерү һәм экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыру зарурлыгын күздә тота торган таләпләр кулланылмый. Шул ук вакытта административ регламентның структурасы һәм эчтәлеге Тәртипнең II бүлегенә туры килергә тиеш.

2. Тәртипнең III, IV бүлекләре гамәлен 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын вәкаләтле оешма тарафыннан килештерүнең, аларга экспертиза үткәрүнед һәм аларны раслауның түбәндәге вакытлыча тәртибен билгеләргә:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары проектларын эшләгәндә һәм раслаганда (алга таба – административ регламент проекты) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләре кулланыла;

коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү максатларында административ регламент проекты дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла;

административ регламентлар проектларына бәйсез экспертиза Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокук актларына һәм норматив хокук актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 24 декабрь, 883 нче карары белән расланган Аерым норматив хокук актларына һәм норматив хокук актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенең III бүлеге нигезендә үткәрелә;

административ регламентлар проектларына экспертиза административ регламентлар проектларына экспертиза үткәрергә вәкаләтле оешма (алга таба – экспертиза, вәкаләтле оешма) тарафыннан үткәрелә;

экспертизаның предметы:

а) административ регламентлар проектларының Тәртипнең 1.3 һәм 1.7 пунктлары таләпләренә туры килүе;

б) карар кабул итү критерийларының Тәртипнең 2.11 пунктындагы дүртенче абзацында каралган таләпләргә туры килүе;

в) проектта гариза бирүчеләр тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга мөмкин булган документларны һәм (яки) мәгълүматны мәҗбүри бирү турындагы таләпләрнең булмавы;

административ регламент проектына экспертиза аны алган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көн эчендә вәкаләтле оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла;

административ регламентны раслау өчен җаваплы башкарма хакимият органы вәкаләтле оешманың бәяләмәсендәге искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алуны тәэмин итә. Эшләп бетерелгән административ регламент проектын вәкаләтле оешмага бәяләмә алуга кабат җибәрү таләп ителми;

административ регламентны раслау турындагы норматив хокукый акт дәүләт хезмәте күрсәтелә торган орган тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелә;

административ регламентлар Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә административ регламентны раслау турындагы боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган яки Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасына тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә административ регламентны раслау турындагы норматив хокукый акт кабул ителгән вакыттан 10 эш көне эчендә вәкаләтле органга «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасын алып баруга җибәрелергә, шулай ук административ регламентны раслаган дәүләт хакимияте башкарма органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

4. 2022 елның 28 февраленә кадәр расланган административ регламентка үзгәрешләр кертү өчен хокукый нигезләр булганда, шул исәптән тиешле дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләрен регламентлаштыра торган закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелгәндә, административ регламентка үзгәрешләр кертү турындагы норматив хокукый акт бу карарның 1 пункты таләпләрен исәпкә алып эшләнә һәм чыгарыла.

5. 1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, Тәртипкә үзгәреш кертергә:

«Бу пунктның беренче, өченче – алтынчы абзацларында күрсәтелгән административ регламентлар дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру вәкаләтләре барлыкка килгән көннән иң күбе 60 календарь көн тәшкил иткән срок эчендә эшләнә һәм раслана дип билгеләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин